ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 16 һәм 33 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында “билгеләнгән тәртиптә” сүзләрен “билгеләнгән тәртиптә алынган” сүзләренә алмаштырырга, “федераль законнарда каралган очраклардан һәм оешма белән идарә итүдә катнашу Россия Федерациясе законнары нигезендә җирле үзидарә органы исеменнән башкарылган очраклардан” сүзләрен “муниципаль берәмлек исеменнән оешманың гамәлгә куючысы вәкаләтләрен башкару яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актларга таянып, муниципаль берәмлек гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен кайгыртудан; федераль законнарда каралган башка очраклардан” сүзләренә алмаштырырга;

2) 33 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

“$2^1$) муниципаль хезмәткәрнең ризалыгы белән генә һәм коррупциячел хокук бозуны кылу фактын тануы шарты белән, хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупциячел хокук бозу кылыну хакында аны кылуның фактагы хәлләре бәян ителгән докладды һәм муниципаль

хезмәткәрнең язмача аңлатмасы (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге җәза бирелүдән тыш);”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 06 октябрь
№ 64-ТРЗ